**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 26 июнь | № 463

г. Казань

Балтач муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Балтачагрохимсервис» ААҖнең Балтач муниципаль районында 49,8 гектар гомуми мәйданлы, Р.М.Нургалиев, Х.Г.Нургалиева, А.Р.Нургалиев, Р.М.Нургалиева, Р.Р.Нургалиев, Р.Р.Хәлимова, Р.Н.Нургалиев, М.Ш.Нургалиева, Г.Ш.Нуриева, Ф.К.Нуриев, Г.А.Нуриев, Р.Нуриева, С.Ш.Нуриеваның гомуми өлешле милкендә булган авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлекләрен 16:12:000000:535 кадастр саны белән кадастр паспортларында күрсәтелгән чикләрдә файдалы казылмалар чыгару максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә күчемсез мөлкәт дәүләт кадастры документларына һәм Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\463.docx